ЮЛ РӨХСӘТЕ
Йөртүчеләргә вакыт турында искәрттеләр
> 2

ЗАМАНЧА КӘСЕП
Иренмәгән кешегә акча эшләү юллары шактый
> 2

КАМАШЕВЛАР ГАИЛӘСЕ:
«Кешеләрдән нинди мөгамәлә көтәсең, үзең дә аларга шундый бул»
> 3

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА
Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 104 (29071) | Шимбә | 22 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

САБЫЙЛАРНЫ ҖӘЕН САНЫЙЛАР

Мәктәпкә әзерлек

Урын юк дип кайгырасы түгел! Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы әти-әниләрне, 1 нче сыйныфка баручы сабыйларның берсе дә урамда калмаячак, дип тынычландыра. Шул ук вакытта мәктәп җитәкчеләрен дә кисәтәләр: укырга алганда, бернинди сынаулар да үткәрергә ярамый. Быел республикада 57 мең бала тәүге тапкыр парта арасына утырыр, дип фаразлана.

Авылда балалар юк, шәһәрдә исә мәктәпләр җитми. Шулай да биш ел эчендә 1 нче сыйныфка баручылар саны 7 меңгә күбәйгән. Кайбер районнарда демография үсеше әллә ни зур булмаса да, ике районда бу сан шактый ишәйгән. Әйтик, шушы вакыт эчендә сабыйлар Питрәчтә – 3,5, Әлмәттә 2 тапкыр арткан. Министрлыкның гомуми белем бирү идарәсе башлыгы Татьяна Алексеева белдергәнчә, әлеге ике районда 1 нче сыйныфка кабул итү буенча вазгыять борчу тудыра. Питрәч районының Көек авылындагы «Алгоритм» технологик лицеенда 150 гаризага күбрәк тапшырганнар. «Әмма борчылырга кирәкми. Буш урыннарга парталар куеп, өстәмә сыйныфлар ачачакбыз», – ди белгеч. Әлмәт шәһәрендә исә әти-әниләрнең күбесенең балаларын инженерлык лицеена бирәсе килә икән. Анда беренче сыйныфка гариза биргән 220 баланың 192сен генә алачаклар. Ә исемлеккә эләкмәүчеләргә күрше мәктәпләрдә урыннар тәкъдим ителәчәк.

Әзерлек төркеменә йөреп кенә мәктәпкә эләгеп булмый. Кагыйдәләр барысына да бертигез. Ә менә бертуганнар өчен тәртип башкачарак. Апасы кайда укыса, мәктәп җитәкчелеге сеңлесен дә шунда кабул итәргә тиеш. Хәрби, полиция вәкилләре, судья, Тикшерү комитеты хезмәткәрләренең балаларын урнаштырганда да өстенлек бирелә.

Министрлыкның Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе урынбасары Светлана Захарова белдергәнчә, хәзерге вакытта әти-әниләрдән Дәүләт хезмәтләре порталы аша 42 мең гариза кергән. Калганнар аны мәктәпкә барып тапшырган.

– Министрлыкка 1 гыйнвардан бүгенгә кадәр 500 мөрәҗәгать килде. Баштарак әти-әниләр 1 нче сыйныфка кабул итү кагыйдәләре белән кызыксынды. Соңгы шикаятьләр буш урыннар булмауга бәйле. Иң күбесе Питрәч (125), Әлмәт (21), Лаеш (10) районнарына туры килә, – диде Светлана Захарова.

Питрәч районында 1 нчегә генә түгел, 2–9 сыйныф укучыларын кабул итүдән баш тарту очраклары да бар икән. Шундый 147 гариза кергән. Лаеш районындагы Усад һәм Столбище мәктәпләрендә дә укучылар саны ике тапкыр арткан. Шуңа күрә кемнәргәдер автобус белән Олы Кабан, Комлы Кавал мәктәпләренә йөрергә туры килмәгәе.

Урын җитми дип, сыйныфларны балалар белән шыплап тутыру укуга зыян китермәсме соң? Бер сыйныфта 33–36 укучы булачак бит. Татьяна Алексеева, укучы саны күп булу сыйфатка комачауламый, дип тынычландыра. Бу урында ул яңа уку елыннан барлык мәктәпләр өчен дә бердәм программа кертеләчәген искәртте. Бер мәктәптән икенчесенә күчкәндә, укуда кыенлыклар тумаячак, димәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

– Улыбыз Аязга – 6 яшь. Быел 1 нче сыйныфка бара. Гаризалар тапшырдык инде. Класста балалар 30дан да ким булмаячак. Без ирем белән балалар мәктәпкә үзләре йөрергә тиеш дип саныйбыз. Шуңа күрә шәһәрнең бер башыннан икенчесенә йөртү яклы түгел. Укытучыны сайлап булмый, кайсы эләгә инде. Аптырыйсы юк. Хәзер әти-әниләр укытучыны ошатмаса, дәррәү килеп алыштырып та куя, – ди Казанда яшәүче күпбалалы әни Гөлүзә Василова.

Баулы шәһәрендәге 5 нче мәктәпнең директор урынбасары Рамилә Бәдриева исә әти-әниләргә укытучыны сайламаска куша.

– Беркөнне базарга барган идем. Шунда бер сатучы: «Оныгымны кайсы мәктәпкә бирим икән?» – дип сорады. «Бар мәктәп тә шәп, бар укытучы да яхшы укыта», – дидем. Шәһәр кечкенә булгач, бер-берсенә бәя бирү дигән нәрсә бар. Берәүгә бер укытучы ошамаса, икенчесенә әйтә дә, шуны бер-берсенә тараталар. Һәм ул иң начарга әйләнә. Бу бер дә дөрес түгел. Балаларны укырга биргәндә, укытучыны сайламагыз. Укытырга куйганнар икән, ул үз эше өчен җаваплы. Яшьләргә дә ышанырга кирәк. Алар арасында өлкәннәргә караганда күпкә кызыклырак эшләгәннәре бар. Энергияләре күп, иҗади булырга омтылалар, – ди Рамилә Бәдриева.

Балалар бакчаларына килгәндә, бары Питрәч районында гына урыннар җитми. Көек һәм Царевода яңа йортлар төзелеп, яшь гаиләләр күченүгә бәйле бу. Шуңа күрә бакчалар буш түгел. Көектәге әти-әниләрнең күбесе шәһәргә барып эшли. Алар сабыйларын Казан бакчаларына йөртә ала. Сүз уңаеннан, быел Казанда – 2, Чаллыда, Мамадыш, Биектау, Әлки, Тукай районнарында яңа бакчалар төзеләчәк.

– Бала 2–2,5 яшькә җиткәндә, әти-әниләр аның үсеше турында борчыла башлый. Табиб, логопед, психологларга йөртү ихтыяҗы туарга мөмкин. Соңгы вакытта сабыйларда тел кимчелекләре, психологик яктан тоткарлыклар күзәтелә. Шуңа күрә бакчага йөрмәгән сабыйлар өчен консультация үзәкләре булдырылды. Республикада аларның саны – 220. Әниләр анда балалары белән бергә йөри ала, – ди Татьяна Алексеева.

Сәрия МИФТАХОВА

Көпчәкле музей

«Җиңү поезды» күчмә күргәзмә-музее Татарстанның өч шәһәрендә – Нурлат, Казан һәм Чаллы вокзалларында тукталыш ясаячак. Ул иртәгә – 23 июльдә Самарадан Нурлатка килә. Экспозиция белән 24–26 июльдә – Казанда, 27–28 июльдә Чаллыда танышып булачак. Күргәзмә-музей тимер юл вокзалларында бушлай эшләячәк.

Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева әйтүенчә, көпчәкле музей Бөек Җиңү рухын тою мөмкинлеген бирә. «Республикада яшәүчеләрнең үз тарихын күбрәк беләчәкләренә һәм күргәзмәгә балаларын да алып киләчәкләренә ышанам. Әйдәгез, каһарманнарыбыз истәлеген яшь буынга тапшырыйк», – диде ул.

«Җиңү поезды» – хәрәкәтләнүче поездда урнаштырылып, шул вакыйгаларга чумган кебек тәэсир калдырган дөньядагы тәүге күргәзмә. Ул Бөек Ватан сугышының аерым вакыйгаларына багышланган 10 вагоннан тора. Музейга бушлай билет алу өчен поездпобеды.рф сайтында теркәлергә (поезд килергә бер тәүлек кала) кирәк. Экспозиция иртәнге уннан кичке җидегә кадәр эшли.

Унсигездән – утызга

Армиягә чакырылыш буенча 18дән 30 яшькә кадәр алачаклар. ТАСС хәбәренә караганда, хәрби хезмәткә чакыру яше турында закон проектында 18дән 30га кадәр яшь аралыгы күздә тотылган. Дәүләт Думасының Оборона комитеты рәисе Андрей Картаполов әйтүенчә, комитет закон проектын икенче укылышта караганда шундый төзәтмәне хуплаган. «Төп төзәтмә – армиягә чакыру яшенең иң югары чиген 30 яшь итеп билгеләү, ә иң түбән чиген 18 яшь итеп калдыру турында карар ителде», – дигән ул.

Аның сүзләренә караганда, түбәнге чикне 18 яшь итеп калдыруның сәбәбе күп кенә егетләрнең нәкъ менә 18дә хезмәт итәргә теләвенә бәйле. Шул ук вакытта Картаполов ачыклап үткәнчә, армиягә чакыру яше турында яңа нормалар быелгы көзге чакырылышка кагылмый. Исегезгә төшерәбез: башта закон проектында армиягә чакыру яшенең иң түбәнге чиген 21 яшькә җиткерү күздә тотылган иде.

Яңалык

Хәләл акча

ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫНДА ИСЛАМ БАНКИНГЫНА БӘЙЛЕ ЗАКОН КАБУЛ ИТЕЛДЕ

Шәригать кушканча исәп-хисап. Шушы көннәрдә Дәүләт Думасында ислам банкингына бәйле закон кабул ителде. Сынау рәвешендә аны илнең дүрт төбәгендә гамәлгә ашырачаклар. Шул исәптән Татарстанда да.

Закон нәрсә турында?

Ислам банкингы турындагы законны Россия Дәүләт Думасы икенче укылышта кабул итте. Документ нигезендә банкларга клиентларга шәригать нормалары кысасында хезмәт күрсәтү рөхсәт ителә.

Ислам банкингын сынау ике ел – 2023 елның 1 сентябреннән 2025 елның 1 сентябренә кадәр дәвам итәчәк. Экспериментта Башкортстан, Татарстан, Дагыстан һәм Чечня катнаша.

ИСЛАМ БАНКИНГЫ УЛ:
- ✓ табышны да, зыянны да банк һәм клиентның үзара бүлүенә нигезләнә;
- ✓ ссудалы процентлар юк;
- ✓ банклар тәмәке, хәмер, корал, комарлы уеннарга корылган бизнесны финансламый;
- ✓ спекуляция тыела;
- ✓ экспериментта катнашучы банклар физик яки юридик затларга раса, милләт, тел яки дини билгеләре буенча хезмәт күрсәтүдән баш тарта алмаячак;
- ✓ сату-алуда ана капиталын куллану мөмкинлеге бар.

shutterstock.com

Ислам банкингының үзенчәлеге нидә соң? Билгеле булганча, ислам банкингы традицион банк системасыннан аерылып тора һәм дингә таяна. Коръәндә риба тыела, бу гөнаһ санала, чөнки дин буенча җиңел генә алган табыш хупланмый. Процентларга алмаш булып, аз да түгел, күп тә түгел – ышанычка нигезләнгән партнерлык (шарика әл-вуҗух) килә.

Сүз уңаеннан, соңгы мәгълүматлар буенча, дөньяда ислам финансларына җәлеп ителгән акча күләме 3 триллион долларны тәшкил итә. Көнбатыш санкцияләре эчендә яшәвебезне исәпкә алып, әлеге законны актуаль һәм вакытлы дияргә нигез бар. Ислам дөньясы илләре белән мөнәсәбәтләрне дә онытырга ярамый. Бу законны кабул итү чын-чынлап Көнчыгышка йөз тотуны аңлата.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Анатолий АКСАКОВ, Дәүләт Думасының Финанс базары буенча комитеты башлыгы:

Пенсияләр һәм пособиеләрне санлы сум (цифровой рубль) белән алуга ихтыяҗ булса, ул тиз арада әйләнешкә кереп китәчәк. Безнең IT белгечләр бу җәһәттән төрле вариантлар тәкъдим итә. Тик башта сынап карарга һәм иң мөһиме: кешеләргә сайлау мөмкинлеге калдырырга кирәк. Бер очракта да мәҗбүриләү булмаячак. Акчалата алырга телиләрме яки картагамы – алсыннар. Бу – хокук, ә бурыч түгел.

(«Аргументы и факты» газетасыннан)

РОССИЯДӘ – КАРЬЕРА

«Работа.ру» һәм GeekBrains хезмәтләре оештырган сораштырудан күренгәнчә, Россиядә яшәүче һәр икенче кеше һөнәрен алмаштырырга тели.

НИНДИ ҺӨНӘРЛӘР БЕЛӘН КЫЗЫКСЫНАЛАР?

28%	IT тармак	9%	кино һәм музыка
24%	персонал белән идарә итү	7%	медицина
17%	психология	5%	компьютер уеннары индустриясе
17%	дизайн	4%	ветеринария
10%	маркетинг, реклама	4%	мода

Тыюлыкның – үз кагыйдәсе

Җәй башыннан Биоресурслар буенча дәүләт комитеты республика тыюлыкларында тиешле кагыйдәләрне бозган 62 кешене җаваплылыкка тарткан. Ведомствоның матбугат хезмәте хәбәренә караганда, быел барлыгы 283 кагыйдә бозу очрагы ачыкланган.

Комитет белгечләре кисәтеп әйткәнчә, тыюлыклар чикләрендә табигатькә зыян салырдай гамәлләр кылу, шул исәптән машина белән керү, учак кабызу тыелган.

Моннан тыш махсус сакланылышлы территорияләрдә төзелеш алып барырга ярамый. Комитет хезмәткәрләре «Рус-немец Швейцариясе» табигать ядкәре кебек ял урыннарын аерым игътибар үзәгендә тота.

Бүгенгә республикада 193 тыюлык бар. Гомуми мәйданы – 465,109 мең га. Республиканың гомуми мәйданының 7 проценты бу.

Бозлы-яңгырлы яллар

Бу ялларда Татарстанда яшенле яңгырлар көтелә. Урыны белән боз яварга мөмкин. Һава температурасы көндез +26 градустан артмаячак.

Гидрометеоүзәк хәбәр иткәнчә, шимбә – 22 июльдә көндезге температура 20…+25 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +12…+17. Кайбер районнарда яшенле яңгыр һәм секундына 20 метрга кадәр тизлектә көчле җил булырга мөмкин. Якшәмбе – 23 июльдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +21…+26 градус күрсәтәчәк. Төнлә +11…+16. Кыска вакытлы яңгырлар явып үтәчәк.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, дүшәмбе – 24 июльдә дә яшенле яңгырлар көтелә. Көндез һава температурасы +20…+25 градус тәшкил итәчәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Романтиклар һәм прагматиклар

Былтыр бер танышымның мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган баласы төзелеш институтына риэлторлыкка укырга керде. «Үзе теләп бардымы, әллә сезне – әти-әнисен тыңлап, шундый һөнәр сайладымы?» дигән сорауга җавап: «Әлбәттә, үзе», – булды. Гаҗәпләнәсе юк, бүгенге яшьләр акча исен ерактан сизә. Андый һөнәр шул ук «купи-продай» кимәлендә, ягъни һичбер романтикасыз булса да, күчемсез милек белән эш йөртүнең саллы керем китерүен яшь-җилкенчәк белеп үсә.

Ә без менә яшь чакта акча хакында ялгыш та уйламаучы төзәлмәс романтиклар идек. Ни дәрәҗәдә очучы буласым килгәнне язган идем инде. Яшерен-батырын түгел, әле дә авиациягә кагылышлы видео яисә текст күрсәм, дөньямны онытып, шуны карыйм. Димәк, әлегә чаклы «төзәлмәгәнмен». Бер сыйныфташым, авылдан ерак китә алмасын сизенсә дә, үлеп, диңгезче булырга, диңгез-океаннарны айкап йөрергә ашкынды. Күпләрнең, хәтта артык яхшы укымаганнарның да космонавт булырга хыяллануын әйтеп тә тормыйм. Ә бүгенге үсмер, шул һөнәр хакында сүз чыгуга, беренче: «Космонавт күпме алып эшли соң?» – дип сорый. Шулай, бүгенге яшьләр хыял канатларын җилпеп яшәми, күктән йолдыз чүпләми. Алар – җирдә. Яхшымы бу, начармы? Кистереп җавап бирү җиңел түгел. Тик менә бала чактан ук акчага, байлыкка мөкиббән буынны кайчакта кызганасы, «югалган буын» дип атыйсы да килә. Әмма уңышлылык тулаем акча, байлык белән бәяләнгән бүгенге чорда башкача була ала микән?

«Романтика – хәзер бөтенләй кирәксез әйбер, күкләрдә адашып йөрисең икән, тормышта һичнәрсәгә ирешә алмыйсың», – диючеләр бар. Килешеп бетеп булмый. Романтиканы гади хыялыйлык белән генә бутарга кирәкмидер. Романтизм ул – үзеңә акча, ниндидер бонуслар таләп итми генә олы, хәтта ки бөек эшләргә, максатларга омтылу. Бөек идеаллар хакына илгә, кешелеккә риясыз хезмәт итәргә атлыгып тору. Прагматикка исә аның ише кирәкми, ул андый ук дәрәҗәдә «ычкынмаган». Аңа идея түгел, тотып карап, файдасын күреп була торган әйберләр хаҗәт. Гомумән дә беренче урында ул үзе, үз мәнфәгатьләре.

Прагматизм, бар очракта да димим, тик күпчелек вакыт мин-минлек, эгоизм белән янәшә тора. Прагматиклардан уңышлы бизнесменнар чыга. Капитализмны, гомумән, алар өчен яралган, алар тудырган строй дип атап буладыр. Тик менә акча капчыгы өстендә аякларны селкеп утырып, үзеңне бүгенге дөньяның хуҗасы дип яшәүдә микән соң тормыш мәгънәсе? Прагматикка карьера кирәк, ул үз эшчәнлегеннән максималь керем, матди дивидендлар көтә. Файда эзләгәндә андыйларның бер өлеше әхлак, мораль нормалары белән дә артык исәпләшмәскә мөмкин. Һәм бүген без, ни кызганыч, эгоистлар альтруистлардан күпкә артыграк заманда яшәп ятабыз. Андый холык-фигыль, менталитет безне кая илтеп чыгарачак – әлегә белмибез…

Ә бит гел башка заманнар да бар иде. Бөтен илне «романтиклар ватаны» дип атаган чорлар. Идеалларга – тигезлек, гаделлек, туганлыкка ышанып, шулар хакына яшәгән совет чорын әйтүем. Совет иленә нигез салган Ленинның үзенең дә шундый зат булганлыгы мәгълүм. Мәскәүгә килеп, Ленин белән әңгәмә корган инглиз язучысы Герберт Уэллес пролетариат юлбашчысын тикмәгә генә «Кремль хыялые» дип атамаган. Ә 1980 нче елларга коммунизм вәгъдә иткән Хрущев кем? Ул да прагматиклыктан бигрәк романтик булмаганмы? Совет заманы романтизмы ул – коммунизм дигән идеаль җәмгыятькә, аның җитәчәгенә ышану. Тик яши-яши шуны аңладык: коммунизм кеше табигатенә туры килеп бетми икән бит. Романтикларга туры килгәндә дә прагматиклар аның белән килешми икән.

Кеше затындагы романтизм да, прагматизм да чорга гына түгел, геннарга, тәрбиягә дә бәйле халәттер. Үтә кырыс, мәрхәмәтсез заманнарда да романтик җаннар – шагыйрьләр булган, яшәгән, иҗат иткән. Язучыларда да ул сыйфат җитәрлек. Гәрчә акча эшләү максатыннан гына иҗатка тартылган каләм ияләре булган җәһәттә дә. Бүгенге татар язучылары – тоташ романтиклар, дисәм ялгышмам кебек. Гонорарлар ташка үлчим булганда, гомумән, китап чыгару проблемага әйләнгәндә дә язудан туктамаган, һәрдаим «кәҗәсе түгел, мәзәге кыйммәт», дип яшәгән кавемне башкача кем дип билгелисең? Прагматизм романтизмны аркасына егып салган заманда алай кылануны батырлыкка да санап булыр иде…

Ике төр күңел халәтен чагыштырганда, тагын шунысын да әйтми ярамас: романтик, миңа калса, китапка, гыйлемгә прагматикка караганда ныграк тартыла. Тикмәгә генә совет заманында, бигрәк тә аның соңгы ике-өч дистә елында илдә чын мәгънәсендә китап культы, белем культы чәчәк атмады. Космонавтикадагы уңышлар, алдынгы фән, затлы мәдәният. Сез ул чорда туган фильмнарны – Гайдай, Данелия, Рязанов, Лиознова төшергән кинематография шедеврларын гына карагыз. Ул режиссерлар бүгенгеләр кебек «кассовость» – «бу фильм күпме акча китерер икән?» дип тырышмаган. Чын сәнгать әсәре тусын, дип эшләгән. Һәм тудырган да. Әдәби әсәрнең дә акча хакында гына уйлап язылганы, халтура булмаган очракта да, ниндидер классикага ялгыш та якын килә алмыйдыр. Бу хәл дә классикларны (дөнья, рус, татар классикларын) – дөньяны камилрәк, мәгънәлерәк итәргә теләгән каләм әһелләрен дә башлыча романтиклар отрядына кертә түгелме?

Романтикларның күбесе – пацифистлар, ягъни сугышны кабул итмәүчеләр. Кеше хокукларын яклаучылар, ирек-хөрлек ягында торганнар да – шулар. Күңел халәте, аның нечкәлеге кагу-сугуларны, төрле рәхимсезлекне читкә этәрә. Романтиклар, гадәттә, үз инануларын акчага алыштырмый, сатмый. Ул гынамы, романтиклар идея өчен хәтта корбанга да әзер. Итальян монахы, астроном Джордано Бруноны, мәйдандагы баганага бәйләп утта яндырганчы, Җир Кояш тирәли әйләнә, дигән инанудан баш тартсынга ничә ел төрмәдә тоталар, күпме үгетлиләр – файдасыз. Идея хакына кире беткән булу өчен дә романтиклык шарт.

Прагматиктан аермалы буларак, тормышка романтик күзлек аша карарга гадәтләнгән затка элек тә җиңел булмаган, бүген дә җиңел түгел. Тик романтизм, бүгенге дөньяда аңа урын бик күп булмаса да, барыбер яшәячәк. Хиссез, хыялсыз дөнья кызык булмаганга гына түгел. Җиһан тоташ прагматикларга гына кала икән, ул банкага тутырылган еланнарны хәтерләтмәсә дә, анда рухияткә, яңага, яктыга, батырлыкка урын аз калачак чөнки.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ТУП – БЕЗДӘ

Премьер-лигага әйләнеп кайткан «Рубин» бүген яңа сезондагы тәүге очрашуын уздыра. Казан командасы «Локомотив»ка каршы уйный. Мәскәүгә китәр алдыннан футболчылар һәм аларның тренерлары Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановтан хәеф-фатиха алды. Сүз уңаеннан, моңа кадәр «Рубин»да сезон алдыннан мондый очрашу узганы юк иде.

tatarstan.ru

Билгеле булганча, узган сезонны «Рубин» беренче лигада уздырды һәм анда чемпион калып, кабат иң көчлеләр сафына әйләнеп кайтты. Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, җиңел булмаячак, әмма тырышырга кирәк.

– Төннән соң көн туа. Сезнең өчен дә якты көннәр башлануына чын күңелдән сөенәбез. Андый көннәр күбрәк булсын, кояш ныграк җылытсын. Авыр булса да, яхшы уен күрсәттегез. Яңа сезон алдыннан сезгә зур өметләр баглыйбыз. Сезон җиңел узмас, алга барырга кирәк! – диде Рөстәм Миңнеханов команда белән очрашуда. – Ничек кенә чыгыш ясасагыз да, сез барыбер безнеке. Җиңгән өчен генә яратып, ә җиңелгәч, ачуланып булмый. Бергә сөенәчәкбез, бергә көенәчәкбез. Республика һәм аның җитәкчелеге һәрвакыт сезнең янәшәдә булачак, шуны белеп торыгыз. Клубның идарәсе дә, иганәчесе дә дәрәҗәле, республикада абруйлы җитәкчесе дә бар. Барысы да яхшы булырга тиеш.

Рөстәм Миңнеханов баш тренер Рәшит Рәхимовның тәҗрибәле һәм абруйлы белгеч булуын искә алды.

– Безнең команда рубин кебек ялтырап торырга тиеш. Башкача була да алмый. Спортта кайчак кара полоса да очрый. Әмма бирешергә ярамый, юл ярып алга барырга кирәк, – диде Татарстан Рәисе.

Узган ел команда бер баскычка түбән лигада уйнаса, сезон дәвамында ике тапкыр тренер алмаштырдылар, клубта идарә итү рәвеше дә үзгәрде. Клубның идарә рәисе вазыйфасын Марат Сафиуллин башкара. «Безнең проблемаларны беләсез һәм аларны хәл итәргә булышасыз, – диде ул Татарстан Рәисенә. – Алдыбызда нинди сынаулар барлыгын аңлыйбыз һәм аларны узарга тырышачакбыз.

Баш тренер Рәшит Рәхимов исә уенчыларның кулдан килгәнчә тырышасын әйтте. Озак көтәсе калмады. Инде бүген үк «Рубин» Мәскәүдә «Локомотив»ка каршы уйный. Ел дәвамында яңару һәм үзгәртеп кору кичергән Казан командасы иң көчлеләр сафында кабат үз урынын табарга тырышачак.

Хәләл акча

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Фикер

Айрат ФӘРРАХОВ, Дәүләт Думасы депутаты, Салым һәм бюджет буенча комитет әгъзасы:
– Бу канун Россиядәге 20 миллион мөселманга файдага булачак. Чөнки күпләр, дини карашлары сәбәпле, традицион финанс мөмкинлекләреннән файдалана алмады. Әйтик, кредит алу. Дөньякүләм финанс системасы ислам финанслары өчен дә кулай. Ислам финансларына ихтыяҗ мөселман булмаган инвесторларда да бик зур. Чөнки аның принциплары нигезендә намус, этика һәм башка кагыйдәләр ята. Әлеге мөмкинлектән бик күп компанияләр файдаланырга теләр дип уйлыйм. Аеруча хәләл продукция җитештерүчеләр, ипотека, авыл хуҗалыгы тармагы, төзелеш вәкилләре һәм башкалар. Ислам финанслары үсештә. Безнең өчен дә перспективалар зур. Без Ислам Хезмәттәшлеге Оешмасы илләренә якынаябыз.

Руслан ХӘЛИУЛЛИН, Россия ислам институты каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эксперты:
– Хәләл продукция турында сөйлибез икән, димәк, сүз сыйфат, чисталык турында да бара. Бу кагыйдәләр ислам финанс системасына да салынган. Аннан һәркем файдалана ала. Ислам финансы партнерлык мөнәсәбәтләре нигезендә корыла. Ул киң катлауга исәпләнгән.

Талия МИҢНУЛЛИНА, Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе:
– Республикада партнерлык банкингы белән 16 оешма шөгыльләнә. Шәригать кануннары нигезендә товар, фатир, машина сатып алу мөмкин. Шулай ук инвестиция, ипотека рәсмиләштерү, кыйммәтле кәгазь, акцияләр, җиһаз сатып алу мөмкин. Мондый хезмәтләргә ихтыяҗ артканнан-арта бара. Бу тәҗрибәне ил күләмендә куллану нәтиҗәле булачак.

«ПРАВА»ГА ТУЗАН КУНМАСЫН

Ел башыннан бирле Татарстанда 44 меңнән артык машина йөртү таныклыгы бирелгән. Бу узган ел белән чагыштырганда 30 процентка кимрәк. Аның каравы теркәлгән машиналар шулкадәр арткан. Автоинспекция вәкилләре документлар белән йөргәндә нәрсәгә игътибар итәргә кирәклеген әйтте.

Быел Татарстанда халыкка дәүләт автоинспекциясе эшчәнлегенә бәйле 246 меңнән артык дәүләт хезмәте күрсәткәннәр.

– Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе биш төрле дәүләт хезмәте күрсәтә. Алар арасында иң киң таралганнары – машина йөртү таныклыгы бирү һәм транспорт чарасын теркәү. Күрсәтелгән дәүләт хезмәтләренең 97 проценты нәкъ менә шуларга туры килә. ЮХИДИнең теркәү-имтихан алу бүлекчәләренә көн саен якынча 1300 кеше мөрәҗәгать итә. Эшне җиңеләйтү өчен халыкка алдан ук Дәүләт хезмәтләре порталы яки телефон аша язылу мөмкинлеге бар. Бүлекчәләргә үзегезгә уңайлы көнне һәм уңайлы вакытта килә аласыз, – дип сөйләде «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында республика дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы урынбасары Дамир Бикмөхәммәтов.

Аның сүзләренә караганда, быел республикада барлыгы 44 мең 976 машина йөртү таныклыгы бирелгән. Шуларның 16 мең 285ен тәүге тапкыр имтихан тапшыручылар алган. Халыкара машина йөртү таныклыгын исә 2 мең чамасы кешегә биргәннәр. Дамир Бикмөхәммәтов искә дә төшерде: ил күләмендәге машина йөртү таныклыгы – ун, халыкара дәрәҗәдәгесе – өч, әмма илкүләм машина йөртү таныклыгының гамәлдә булу вакытыннан артмаган чорга бирелә. Ягъни әгәр сез машина йөртү таныклыгын моннан сигез ел элек алгансыз һәм быел халыкара документка гариза тапшыргансыз икән, ул сезгә ике елга гына биреләчәк. Чөнки беренчесен яңарту вакыты килеп җитә.

– Алдагы елның шушы ук чоры белән чагыштырганда машина йөртү таныклыгы алучылар саны 32 процентка кимеде, – ди җитәкче урынбасары. – Таныклыкны алмаштыручылар да азрак. Соңгысы, иң беренче чиратта, Россия Хөкүмәте тарафыннан былтыр гамәлгә кергән карарга бәйле. Билгеле булганча, 2022 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдән чыгачак таныклыкларның вакытын өч елга озайттылар. Әмма без документ алмаштыручыларга 2025–2026 нчы еллар җиткәнне көтмәскә киңәш итәбез. Чөнки ул вакытта 2015, 2016 елларда машина йөртү таныклыгы алган кешеләрнең дә чираты җитәчәк.

Татарстан дәүләт автоинспекциясе китергән саннарга караганда, быел республикада 193 меңгә якын транспорт чарасын теркәгәннәр. Узган ел белән чагыштырганда, утыз процентка диярлек күбрәк «тимер ат» исәпкә алынган. Мондый мәшәкать белән йөрүчеләр май – август, октябрь – гыйнвар айларында күбрәк икән.

– Транспорт чарасын, сатып алганнан соң, ун көн эчендә теркәргә кирәк, – дип тә искә төшерде Дамир Бикмөхәммәтов. – Югыйсә административ хокук бозу турында штраф түләргә туры киләчәк. ЮХИДИ инспекторлары юлда мондый машинаны туктатса, беренче очракта – 800, ә әлеге хәл кабатланса, 5 мең сумга кадәр штраф язачак. Өч айга кадәр «права»дан колак кагу куркынычы да бар. Теркәү бүлекчәләрендә дә мондый ваемсыз кешеләргә, мәсәлән, 2 мең сумга кадәр штраф яный.

Рульдә йөрүчеләр җаваплы булырга тиеш, әлбәттә. Бу хакта әле яңа гына Чаллы ЮХИДИ идарәсе башлыгы Радий Кадиков та әйтте. «Рульдә мигрантлар булырга тиеш түгел, – диде ул җәмәгать транспорты турында сөйләгәндә. – Сүз дә юк, төзелештә, заводларда эшләсеннәр. Әмма дистәләгән кеше утырган автобуста түгел. Алар бит – безгә вакытлыча килүчеләр… Бүген – монда, иртәгә исә эзләп тә таба алмассың. Алар телне дә, юллардагы вазгыятьне дә, юлда йөрү кагыйдәләрен дә камил белми».

Ә Казанда исә һәр икенче автобус йөртүчесе диярлек – читтән килүчеләр. Бу уңайдан «ВТ» хәбәрчесе Дамир Бикмөхәммәтовтан аңлатма бирүен сорады.

– Чит илдән килүчеләргә машина йөртү таныклыгы алуның ике генә юлы бар. Беренчедән, кеше таныклыкка инде укыган булса, без ул яшәгән илгә моны

Илдар Мөхәммәтҗанов

раслауны сорап, хат җибәрәбез. Укуы расланса һәм чит ил таныклыгы халыкара конвенциягә туры килсә, мигрантка имтихан тапшырган һәм медицина тикшерүе узганнан соң, укымыйча гына таныклык бирелә. Ә читтә алган «права» конвенциягә туры килмәсә яки ул гомумән дә булмаса, укырга туры киләчәк, – диде җитәкче урынбасары. – Мондый очракта стажга да карап тормыйбыз. Берсендә утыз ел стажы булган ир-атның имтихан тапшырганын карап тордым. Теорияне бирде, ә практика өлешен – юк. Ни өченме? Чөнки күнекмәләрне югалткан. Көндәлек тормышта көн саен эстакадага менәргә туры килми, әлбәттә. Тик юлга чыкканда белем дә кирәк.

Эльвира ВӘЛИЕВА

ҺӘР ЧОРНЫҢ – ҮЗ КӘСЕБЕ

Авыл капкасы

Заманына күрә тормышы да, кешесе дә, кәсебе дә үзгәрә. Элегрәк һәр төбәкнең, һәр авылның үзенә күрә бер һөнәре булса, хәзер теләгән һәр кеше үзенә яңа шөгыль таба ала. Алар иренми, курыкмыйча, тәвәккәлли. Шуның белән тормышын да алып бара.

vk.com

Никадәр генә заманны тиргәсәк тә, бүген уңганбулган, иренмәгән кешегә акча эшләү юллары шактый. Кулыннан эш килгәннәр төзелештә, юктан да акча «ясый» белгәннәр сәүдәдә уңышка ирешсә, шәхси техникасы булганнарга да ел әйләнәсе эш бетеп тормый. Бигрәк тә йөк ташучыларга, авыл тормышы өчен кирәкле барлык тагылма машиналары булучыларга заказлар күп. Дөрес, бу ихтыяҗлар айлап, көнләп үзгәрә, «базар җиле» диләр аны. Әйтик, берничә ел элек кенә авылда бөтен кеше җир эшкәртергә үз техникасы булган кешеләргә карап торса, соңгы елларда мини-трактор, мотоблок, прицеплар сатып алучылар көнләп арта.

Өендә сату өчен кондитер ризыклары, ярымфабрикатлар, тәрәзә кәрнизләре, ишек яңаклары, җиһазлар, хуҗалык өчен кирәкле су багы, мунча мичләре ясаучылар, төсле калайдан почта тартмалары, төрле бизәкләр эшләүчеләр дә, суыткычлар, аппаратура-техник җиһазлар ремонтлаучылар, яшелчә, чәчәк үсентеләре үстерүчеләр… тагын әллә ниләр белән шөгыльләнүчеләр бар: район газеталарының соңгы бите тулы игълан – шалтырат кына, һәммәсен китереп бирәбез дип торалар. Социаль челтәрләрдәге сатам-алам төркемнәрендә дә ниләр генә юк. Әле тагын шунысы гаҗәп һәм сокландыра: андый үткеннәр кешегә нәрсә кирәген бик яхшы аңлый. Әйтик, соңгы елларда авылларда да кешеләр матурлыкка, үз сәламәтлегенә игътибар итә башлады. Парикмахер һөнәре берничә ел инде бик керемле иде. Аларга каш-керфек ясаучыүстерүчеләр, маникюр-педикюр белән шөгыльләнүчеләр көндәшкә әйләнде. Шулай ук массаж, сөлек белән дәвалаучылар янына хиджама ясаучылар, төрле челтәрле бизнесларга кереп, бик тә шифалы препаратлар сатучылар, тәкъдим итүчеләр дә күпләп кушылды. Соңгы бер мисал: эссе көннәр башлангач, кондиционерлар алып килеп, урнаштырып бирүчеләр артты.

Гомумән, без хәзер инде бөтен нәрсәне алып килеп, урнаштырып бирүгә, өйгә килеп, эшләп китүгә күнегеп барабыз. Һич гаепләвем түгел, авыл кешесе дә үз тормышын җиңеләйтергә хаклы лабаса. Икенче ягы бар, әлбәттә: балалар болай да мәктәптә элекке кебек балта-пычкы, башка корал тотарга өйрәтелми, өйдә дә бик күпләр аны өйрәтүне кирәксенми. Юкса авылларда инде вак-төяк ремонт эшләренә кеше табу авырлаша бара. Кулы һөнәр белгәннәрнең аның белән «вакланырга» вакыты да, теләге дә юк, әйтердәй кеше дә, эш белүчесе дә кимеп бара.

Хәзер туй-мәҗлес үткәрүчеләргә алып баручы, музыкант эзләп тә аптырыйсы түгел. Моннан егерме еллап элек үсеп чыккан тамада дигән кәсепчеләр озын гомерле булды: бүгенгәчә эшсез тилмермиләр, хезмәт хаклары да шәп. Чорлар-еллар алмашса, үзгәрсә дә, авылларда әле су-җылылык кертүчеләр, мич чыгару-плитка ябыштыручылар, капка-койма эшләүчеләр, машина ремонтлаучылар да – иң кирәкле һөнәрләрдән. Шәһәрләрдә инде ялланып бала караучылар, һөнәри өй җыештыручылар күптән бик популяр булса, алар да акрынлап авылларга килә. Дөрес, әлегә ялланып бала караучылар турында ишеткән юк, ә менә өй җыештыручылар, идән паласлары юучы-чистартучылар хезмәтеннән файдаланучылар арта. Нигә, әйбәт бит! «Акчаң булса, кино буш» дип, сөенә-сөенә, эшләрне җиңеләйтәбез. Дөрес, аңа карап буш вакыт артмый. Элек барысын үзе, үз куллары белән эшләгән әти-әниләр, әби-бабайлар ни хәлләр җитешкән дип зарланабыз.

Соңгы елларда авылда популярлашып киткән тагын бер һөнәр ияләре барлыкка килде. Элегрәк авылда тояк караучы дигән кеше гомумән булмады. Ат дагалаучылар булган, тояк караучылар юк. Авылда сыер тоягын кистерү, тигезләтү, карату дигән нәрсә дә ишетелгән әйбер түгел иде. Булса да, бик сирәк булгандыр. Бу турыда аптырап сөйләшкәндә без үзебез, безнең маллар гомергә ташлы җирдә йөрде, тояклары ташларга ышкыла-кырыла, ашалып беткәндер, дибез. Ә хәзер маллар тигез, йомшак болынлыкта йөри. Бәлки сәбәп шунда гынадыр дияр идең, авыл терлегенең генә түгел, хуҗалык сыерлары тоягында да мең дә бер проблема бит. Күп еллар элек чит илдән кайтарылган терлекләр «бүләге» буларак, хуҗалыклар да тояк авырулары белән тилмерә. Малны тиз арада «эштән чыгара» торган бик көчле инфекцион, йогышлы авыру бу. Вакытында чарасын күрмәсәң, бөтен көтүеңә тиз арада тараласын көт тә тор. Проблеманың җитдилеге шуннан да күренә: хәзер хуҗалыкларда мал табибы, терлек караучы, зоотехник кебек, штатлы тояк караучылар да бар. Берәр генә дә түгел. Аларга авыл кешесенең дә йомышы әледән-әле төшеп тора. Тояк карау дигәч тә, әй, дип кул селтәргә ярамый. Үзебезнең сыерның тоягы үзенчәлекле булу сәбәпле, елга берничә мәртәбә «педикюр» хезмәтеннән файдаланырга туры килә. Шөкер, кемгә әйтим икән дип аптырыйсы түгел: бу эшнең кирәклеген аңлаган күрше авыл егете үзе махсус станогын ясаткан. Бик уңайлы, шалтыратасың, килә, эшләп китә. Бәясе дә билгеле. Язгы чорда гына чираты күп. Тагын бер замана кәсебе шул…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ТУГЫЗ БАЛА ҮСТЕРҮЧЕ КАМАШЕВЛАР:

«ГАИЛӘДӘ БЕР ФИКЕРДӘ БУЛЫРГА КИРӘК»

Кешеләрдән сиңа карата нинди мөгамәлә көтәсең, үзең дә аларга шундый бул. Чабаксарда узган «Идел буе төбәгенең уңышлы гаиләсе» бәйгесендә җиңү яулаган Камашевлар гаиләсенең яшәү кагыйдәсе әнә шундый.

Камашевларның гаилә архивыннан

Лия һәм Алексей Камашевларның киң җылы кочакларында тугыз бала үсә. Иң олы уллары – Лев атлы егеткә 17 яшь булса, иң нәниләре Семен күптән түгел ике яшен тутырган. Дүрт балага гомер биргән бу күркәм гаилә тагын биш баланы тәрбиягә алган.

– Гаиләдә без – 11 кеше. Балаларыбыз – Лев, Илмир, Ислам, Әнвәр, Ралинә, Азалина, Айнур, Елизавета һәм Семен. Моннан 18 ел элек ирем Алексей белән мәңге бергә булырга вәгъдәләшкән чакта гаиләбез зур булыр дип уйлаган идек уйлавын, әмма бу кадәр зур булыр дип күз алдына да китермәдек, – дип елмая Лия ханым.

Дөрес, «Идел буе төбәгенең уңышлы гаиләсе» бәйгесендә тагын да зуррак гаиләләр белән танышу бәхете елмайган аларга. Ләкин Камашевлардан да көчлерәк гаилә табылмаган.

– Әлеге конкурска без Татарстанда уздырыла торган «Нечкәбил» бәйгесе аша килдек, дисәк, дөресрәк булыр. «Нечкәбил»дә катнашу үзе бер зур сынау, тәҗрибә булды. «Идел буе төбәгенең уңышлы гаиләсе» бәйгесендә катнашырга тәкъдим килеп ирешкәч, озак уйлап тормадык – ризалаштык. Округ күләмендә уздырыла торган бәйге булгач, ул безне тагын да берләштерер, балалар өчен кызыклы тәҗрибә булыр, дигән фикер туды. Һәм ул шулай булды да. Бәйгегә әзерләнгәндә, без көне буе диярлек бергә булдык, мәдәният йортына барып та, өйдә дә мәш килдек. Кыскасы, бик күңелле булды ул, – дип уртаклашты Лия Камашева.

Бәйгедә «Гаилә визиткасы», «Иҗади номер», «Викторина» һәм «Төбәк турында сөйләү» кебек этапларны узган алар. Берсеннән-берсе сәләтле балалар тәрбияләүче гаиләгә җиңү әллә ни авыр бирелмәгән. Уллары Илмир оста итеп баянда уйный, Әнвәр матур итеп шигырьләр сөйли икән. Олы уллары Лев – программист, Ралинә белән Лизага – тимераякта шууда, ә Исламга йөгерештә тиңнәр юк. Аларның «гаилә палитрасы»на оста куллы Азалина белән Айнур ямь өстәп тора.

– Дөресен генә әйткәндә, бәйгедә җиңәрбез дип уйламаган идек. Башкаларның иҗади чыгышларын күреп, бераз күңелсез дә булып алган иде. Әмма жюри нәкъ менә безнең чыгышларның үзенчәлеген тоеп алган, күрәсең. Алар бит башкаларныкына һич тә охшамаган иде. Аларның видеоязмаларын Чабаксардан кайткач та кат-кат карыйм. Балалар булдырдылар. Кызык-кызык мизгелләр булса да, алдан уйланганча килеп чыкты, – дип уртаклашты әңгәмәдәшебез.

Әлеге җиңүнең әһәмияте турында кызыксынабыз.

– Беренче чиратта, бу җиңү безнең гаиләнең бердәм булуын һәм бергә чакта барысын да булдыра алуыбызны раслады. Уңыш сере, дисезме? Менә шул бердәмлектәдер, мөгаен. Гаиләдә һәркем бер якка карарга тиеш бит ул, – дип җавап бирде Лия ханым.

Камашевлар гаиләсен җырлап-биеп кенә ята дип уйлый күрмәгез тагын. Эш арасындагы шөгыль генә алары. Әле берничә ел элек башкалада яшәгән бу гаилә Биектау районының Усад авылына кайтып төпләнә.

– Кечкенә генә хуҗалыгыбыз бар. Ике ат, кәҗәләр, тавык һәм үрдәкләр асрыйбыз. Өйдә дә зоопарк кебек: биш песиебез, тутый кош (попугай) һәм ташбакабыз бар. Йортыбызны приюттан алып кайткан этләр саклый. Һәркемгә – берәр җан иясе, диярсең (*көлә*). Кызык тоелса да, дөресе шул инде аның. Олысының да, кечесенең дә – үз вазыйфасы. Кемдер абзарда эшли, кемдер – өйдә. Хәзер балаларны өйрәтеп торасы юк: барын да үзләре беләләр, – дип, йортларындагы тәртипләр белән таныштыра хуҗабикә.

Балалары хезмәт белән тәрбияләнә аларның. Үзләренә генә хас гаилә кагыйдәләрен дә истән чыгармыйлар.

– Безнең йорттагы төп кагыйдә: «Кешеләрдән сиңа карата нинди мөгамәлә көтәсең, үзең дә аларга шундый бул». Тормышның теләсә кайсы өлкәсенә бара торган алтын сүзләр бу. Һәм, әлбәттә, барыңа да бер өстәл янында җыелышырга да кирәк, – дип йомгаклады сүзен Лия ханым.

Сораштыру

Санаулы җәй

Балалар көтеп алган җәйге каникулның яртысы узып та китте. Җәйге чорда кайбер әти-әниләр балаларын авылга алып кайтса, икенчеләре төрле лагерьларда ял итүләрен кулай күрә. Быел ял итү генә кулай булмагандыр. Чөнки, билгеле булганча, республикада балалар лагерьларына юллама өчен түләнгән акчаның бер өлешен кире кайтару (кешбэк) программасы туктатылды. Балалар җәйләрен ничек уздыралар? Аларның җәйге ялына карата әти-әниләр нинди фикердә? Без әнә шуларны белештек.

Әнисә РӘХИМОВА, күпбалалы әни:
– 4 малаем янымда, җәйге ялларын Казанда, өйдә уздыралар. Лагерьларга бармыйлар, мин дә җибәрмим. Бик ышанып бетермим, анда ризык та хәләл түгел. Узган җәйләрдә мөселман лагерьларына баргаладылар. Баязит, Нурислам, Галиәскәр, Исмәгыйльгә бер-берсе белән дә бик күңелле. Су коенабыз, бакчада эшлибез, дус малайлары килә, бергә уйныйлар. Әле менә чия җыйдык. Берәр кая ял итәргә бару теләге дә бар иде үзе, әлегә барып чыкмый. Безнең өйдә әби бар, аны калдырып китеп булмый.

Әмир МАМИН,
Татарстан Әтиләр берлеге рәисе урынбасары:
– Безнең республикада балаларның җәйге ялын уздыру мөмкинлекләре бик күп. Һәртөрле форматтагы җәйге лагерьлар бар: спорт, мәдәни, белем бирү юнәлешләреннән башлап, яр буендагы урыннарга чыгуга кадәр. Күпчелек әти-әниләр балаларның үзләре янында ял итүен кулай һәм файдалы күрә. Җәйге чорда бала бары тик ял итәргә тиеш дип саныйм. Үзләре теләгәнне эшләсеннәр. Өч улым бар. Берсе спорт лагерена барырга тиеш иде, авырып китү сәбәпле, бара алмады. Хәзер каникулын өйдә, авылда үткәрә. Олы улым инде 15 яшьлек зур егет, әби-бабайларына төрле өй эшләрендә булыша. Авылда эш күп, күңелсезләнергә вакыт юк. Ә каядыр ял итәргә барырга хәзер куркыныч. Бәлки, Петербургка яки Мәскәүгә барып кайтырбыз.

Алсу ФАЗЛЫЕВА, җырчы:
– Җәйге каникулда балалар әбиләрендә авылда булып килделәр, әле күптән түгел бер атнага Төркиягә ялга барып кайттык. Олы улыбыз Аяз – спортчы, июль аенда гына ял итә, ай ахырында җыеннары башлана. Чабаксарга тренировкаларга китәчәк. Уртанчы улыбыз Ильяс футболга, фотомодель мәктәбенә йөри. Кечкенәбез Зифа исә – балалар бакчасында. Үзебезнең эшләр булгач, шунда бирдек тә, инде бер елга якын рәхәтләнеп, яратып йөри. Август аенда ныклап торып мәктәпкә әзерләнергә, репетиторлар белән шөгыльләнә башларга кирәк булыр.

Камилә ГАНИЕВА, быел БДИда химиядән 100 балл туплаган чыгарылыш укучысы:
– Әлегә кадәр уку йортына керү эшләре белән мәшгуль идем. Документлар тапшырдым, медосмотр уздым. Укыган дәфтәрләрне, китапларны җыештырып куйдым. Күңелгә берникадәр җиңел булып калды. Хәзер вакытымны рәхәтләнеп авылда уздырам. Су керергә йөрибез, болынга барабыз, җиләк, мунча себеркесе җыябыз, клубка да чыгабыз. Имтиханнарны тапшырып йөреп, быел лагерьга барып булмады. Әлегә укырга керү турында уйламаска тырышам. Башны ял иттереп, һәр мизгелдән рәхәтлек алам.

Гөлназ СӘФӘРОВА, алып баручы:
– Җәйге ялларда Казан белән авыл арасында йөрибез. Айданны авылга илтеп куябыз, анда әзрәк торып ала да, күңелсез була башлагач, тагын шәһәргә алып киләбез. Укыйсы бер дә килмәсә дә, китаплар укытабыз, әни белән Милли китапханәгә йөриләр. Мәктәптән бик зур исемлек бирделәр, анда 40ка якын китап. Каникулда бернинди түгәрәкләргә йөртмибез. Ел буе инглиз теленә, математикага, бассейнга, тренировкаларга йөри. Җәй көне организмы, башы ял итсен, үзе теләгәнне эшләр өчен мөмкинлек бирәбез. Айдан июнь аенда өч атна «Сәләт» лагеренда булды. Икенче ел инде «Сәләт – Тел» аланына бара. Айданның математикасы бик яхшы, әзрәк телне дә үстерергә телибез. Беренче урында – татар теле, инглиз телен ныгытты, өстәмә рәвештә кытай телен өйрәнде. Бәяләргә килгәндә, быел кешбэк кайтарылмады. Путевка – 30 мең сумга якын. Аңлашыла инде, 3 балалы гаиләгә 90 мең чыгарып салу кесәгә сугачак. Мин һәрвакыт әйтәм: сыйфатлы әйбер арзан була алмый. Бала табасың икән, син аны тулысынча тәэмин итәргә тиеш. Бу кием, ашату-эчерту мәсьәләсе генә түгел, монда шул ук лагерьлар да керә. Кешедән ким-хур булмыйча, баланы һәр яктан үстереп, шәхес буларак тәрбияләргә тиешсең. Иң авыры шушы. Мин биш тиенлек лагерьларга каршы. Хәзерге заманда бигрәк тә куркыныч, Алла сакласын. Берсендә суга батканнар, икенчесендә бетләгәннәр, башкасында агуланганнар... Башка сыймаслык, куркыныч әйберләр бит бу. «Сәләт»кә җибәрәм, чөнки мин андагы даирәне, кешеләрен беләм. Аларга баламны гаиләмә ышанган кебек тапшырам. Бәясенә генә түгел, балаң янында кемнәр булачагына да карарга кирәк.

Ләйсән САФИНА

Илдар Мөхәммәтҗанов

КАЗАННЫҢ БИЮЛЕ КИЧЛӘРЕ

«ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ» БЫЕЛ ДА КАБАН КҮЛЕ БУЕН ГӨРЛӘТӘ

vk.com

Пәнҗешәмбе көнне Казан үзәгендәге Кабан күле яныннан узганда тыпырдаган, шау-гөр килгән тавышлар ишетелеп тора. Аяклар, ирексездән бию көенә баса-баса, шул тавыш чыганагы янына илтә...

Бу хәл җәй буе дәвам итәчәк. Сәбәбе – Казан мэриясе оештыра торган «Хәрәкәттә – бәрәкәт» остаханәләре. Һәр атнаның пәнҗешәмбесендә Кабан күле буенда төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның бию үзенчәлекләре белән танышып, җанлы музыкага биеп, уйнап, көлеп – кыскасы, рәхәтләнеп ял итәргә була.

Гәрчә халык биюләренә багышланган булса да, быелгы проектны бию дәресләре дип кенә чиклисе килми. Алар түгәрәк уен, җыен, аулак өй форматында оештырыла. Ягъни фольклор белән төрле яклап танышу мөмкинлеге бар.

– Казанлылар, башкалабыз кунаклары бергәләп бииләр, халык биюләрен өйрәнәләр, төрле уен коралларының яңгырашын ишетәләр. Аралашу-танышу өчен бию форматында уза торган бик матур чара бу, – ди әлеге проект хакында Казан башкарма комитетының Тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге җитәкчесе Айсылу Лерон.

Инде өченче сезон рәттән уздырыла торган проектның быелгы беренче дәресе 15 июньдә кичке уен форматында узды. Иң элек Татарстан Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең балет артисты Алсу Мәгъсүмҗанова һәм бер төркем биюче безгә «Аваз» перфомансын күрсәткәннән соң, «борма», «өчле тыпырдау», «чалыштыру», «үкчәбаш» дигән серле атамаларга ия булган бию хәрәкәтләрен өйрәтте. Әле тагын дәф, кубыз, курай, таш сыбызгы, саз, кыл-кубыз, думбра кебек борынгы уен кораллары белән дә таныштырдылар. Шунысы күңелле: монда килүчеләр чара ахырына әллә кайчангы танышлар кебек аралаша башлый. Остаханә дәвамында бию хәрәкәтләре аша таныштыралар чөнки. Монда атна саен килүчеләр дуслашып та беткән инде!

Нәкъ бер атнадан бу урынга кабат килдек. Салкын, җилле көн иде ул. Ләкин шәлләрен урап килгән апаларны, туңмас өчен сикереп-сикереп атлаучы балаларны күргәч, яр буена төшмичә үтеп китеп булмады. Бу юлы безне урал татарлары кебек биергә өйрәттеләр. Читек урынына галош киеп биегән кызларны күреп, яннарына бардык. «Электән шулай булган: чыдам аяк киеме дип, урал татарлары галош кигән», – дигән җавап алдык.

Кара һәм кызыл чигүле күлмәк кигән, француз яулык япкан кызларның җиңел генә атлап йөрүләренә карап туймаслык иде. Аякта галош түгел, кроссовка булгангадырмы, башка сәбәпләр аркасындамы – ул кадәр үк җиңел итеп атларга өйрәнеп булмады. Капкалы уйнаганда да уртада калып, җәза үтәргә туры килде.

Ул арада Төркиядән үк килгән «капкадашым» белән сөйләшеп алырга да җай чыкты.

– Таныш сүзләр ишетелгәч, якынрак килгән идек – түгәрәккә алып кереп киттеләр. Казанда, чыннан да, күңелле икән, – диде ул.

Иң таң калдырганы шактый өлкән яшьтәге әбекәйләрнең дә рәхәтләнеп биеп, күңел ачуы булды. Аларны куып җитү түгел, артларыннан өлгерү дә авыр иде. Яшьрәкләрнең арып-талып кырыйга чыгуына көлеп карагандыр инде алар.

Һәр остаханәгә болай ук иркенләп тукталсак, бик күпкә китәр. Шуңа күрә калганнары турында кыскача гына сөйлибез. 29 июньдә чарада катнашучыларны себер татарлары биюенә өйрәттеләр. Дөресрәге, «Ачыр авылы көе», «Чабата» кебек халык җырларына тактага бастырып тыпырдаттылар. 6 июльдә проект кысасында татар һәм башкорт биюләренә багышланган «Дуслык күпере» программасы узды. Җырлы-биюле кичә самавырдан чәй эчеп тәмамланды.

Узган атнада исә чират әстерхан татарлары биюенә җитте. Кабан күле буенда узган чираттагы чара кияүне һәм аның туганнарын кәләш ягында хөрмәтләүгә багышланган «Кияүсый» бию йоласы белән башланып китте.

– Бүген без Саратов гармуны – саз, бәрмә уен коралы – кабал кебек халык уен кораллары белән дә таныштык. Себер татарларының җырларында, көйләрендә Кавказ якларыныкына охшашлык бар, – диде проектның кураторы Лилия Гәрәева.

Ул кичтә «Әстерхан йөреше», «тыпырдау», «тыпырдап аяк тибү», «чүгәләп йөрү» кебек бию хәрәкәтләренә төшендерделәр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Проект турында белешмә

2021 елда уздырыла башлаган «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты җәй дәвамында шәһәрнең Парклар һәм скверлар дирекциясе белән берлектә Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән үткәрелә. Узган сезоннардан аермалы буларак, быел ул тулысынча татар биюен өйрәнүгә багышлана.

Рәсми мәгълүмат

КОМПЛЕКСЛЫ КАДАСТР ЭШЛӘРЕН БАШЛАП ҖИБӘРҮ ТУРЫНДА ХӘБӘРНАМӘ

2023 елның 30 июненнән 15 ноябрьгә кадәрге чорда Татарстан Республикасы территориясендә:

– Югары Ослан муниципаль районы: Октябрь авыл җирлегендә 16:15:150301; Усад авыл җирлегендә 16:16:171401, 16:16:171501; Красносельский авыл җирлегендә 16:16:221201; Дачное авыл җирлегендә 16:16:301201; Чернышевское авыл җирлегендә 16:16:321101;

– Казан ш., 16:33:021144, 16:50:140423, 16:50:221305, 16:50:240201, 16:50:240202, 16:50:250202;

– Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлегендә 16:33:051601;

– Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлегендә 16:42:070401;

– Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлегендә 16:42:200305, 16:42:200306, 16:42:200501, 16:42:200702, 16:42:200703,

30.06.2023 ел, № 923000220/2-ОК дәүләт контракты нигезендә, **комплексны кадастр эшләре башкарылачак**. Заказчысы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы. Почта адресы: Татарстан Республикасы, Казан ш., Вишневский ур., 26 й., телефоны: 8 (843) 221-40-60.

1. Эш башкаручы – кадастр инженеры: ФИО: Мөбарәкшин Рамил Наил улы.

Адресы: 422060, Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т.б., Мотыйгуллин ур., 24 й.

Почта: filial@16.kadastr.ru, телефоны: (843) 514-90-77 (2272).

Идентификация номеры 16-11-289 от 14.03.2011г., «АКИ Поволжье» үзкөйләнешле ассоциациясе әгъзасы булып тора, реестрда – 0153.

Дәүләт контракты төзелгән, хезмәткәре – «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасындагы филиалы кадастр инженеры.

2. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 13 июль, 2015 ел. № 218-ФЗ Федераль законның 69 статьясындагы 4 өлеше (алга таба – Закон) нигезендә, моңа кадәр исәпкә алынган дип саналучы яки үзләре турында мәгълүматлары, Законның 69 статьясындагы 9 өлеше нигезендә, мондый күчемсез милек объектлары турында мәгълүматлар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында (алга таба – ЕГРН) булмаган очракта, ЕГРНга кертелергә мөмкин булган күчемсез милек объектлары хуҗалары хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына мондый күчемсез милек объектларына карата үзләрендә булган материалларны һәм документларны, шулай ук Законның 21 статьясындагы 1 һәм 9 өлешләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә расланып, әлеге күчемсез милек объектларына хокукны раслаучы документлар күчермәләрен тапшыруга хокуклы.

3. Күчемсез милек объектлары хуҗалары комплекслы кадастр эшләрен башлап җибәрү турында хәбәрнамә басылып чыккан көннән соң утыз эш көне эчендә хәбәрнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән кадастр инженерына хәбәрнамәнең 2 пунктында күрсәтелгән адрес буенча күчемсез милек объектына хокукы теркәлгән зат белән, шулай ук үз файдасына күчемсез милеккә хокукны чикләү теркәлгән зат белән элемтәдә тору өчен электрон почта һәм (яки) почта адресы (алга таба – милек хуҗасының элемтәгә керү өчен адресы) турында мәгълүматларны тапшыруга хокуклы, ЕГРНга милек хуҗасының элемтәгә керү өчен адресын кертү һәм алга таба мондый затларга комплекслы кадастр эшләре нәтиҗәләре буенча территориянең карта-планы проектын әзерләүне төгәлләү турында һәм җир кишәрлекләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәр бирү максатында.

4. Комплекслы кадастр эшләре территориясендә урнашкан күчемсез милек объектлары хуҗалары комплекслы кадастр эшләрен башкаруга комачаулык итүгә хокуклы түгел, һәм алар комплекслы кадастр эшләрен башкаручыга график нигезендә билгеләнгән вакытта әлеге күчемсез милек объектларына үтеп керүне тәэмин итүгә бурычлы.

5. Комплекслы кадастр эшләрен башкару графигы

№	Комплекслы кадастр эшләрен башкару урыны	Комплекслы кадастр эшләрен башкару вакыты
	– Югары Ослан муниципаль районы: Октябрь авыл җирлеге 16:15:150301; Усад авыл җирлеге 16:16:171401, 16:16:171501; Красносельское авыл җирлеге 16:16:221201; Дачное авыл җирлеге 16:16:301201; Чернышевское авыл җирлеге 16:16:321101; – Казан ш., 16:33:021144, 16:50:140423, 16:50:221305, 16:50:240201, 16:50:240202, 16:50:250202; – Питрәч муниципаль районы Колай авыл җирлеге 16:33:051601; – Чистай муниципаль районы Кубас авыл җирлеге 16:42:070401; – Чистай муниципаль районы Булдырь авыл җирлеге 16:42:200305, 16:42:200306, 16:42:200501, 16:42:200702, 16:42:200703.	30.06.2023–15.11.2023

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Психолог киңәше

Китаплы җәй

? Җәйге каникул вакытында укыр өчен мәктәптән бик зур исемлек җибәрделәр. Анда, аз да түгел, күп тә түгел – 50дән артык китап. Улым болай да укырга яратмый, иренә. Мәҗбүр итеп тә булмый. Баланы ничек китап укытырга? Кызыксынуын ничек арттырырга?

Фәридә ШАКИРОВА.
Азнакай шәһәре

Балалар психологы Надежда МӘХМҮТОВА:

– Китапка кызыксыну уяту беренче чиратта әти-әнидән тора. Үзегез еш укыйсызмы? Бала кич буе әнисе, йә әтисе китап укып утырганны күрсә, әле хәреф танымый торган бала да китап тотып уйный башлаячак. Еш кына җәйгә бирелгән әдәбият исемлеге мәҗбүри түгел, ә тәкъдим рәвешендә була. Иң башта үз көчеңнән килгән әсәрләрне сайлап алырга кирәк. Бәлки, бу өч яки биш, йә аннан да күбрәк китап булыр. Балага һаман саен әлеге әдәбият исемлеген искә төшермәгез. Чөнки 50 әсәр баланы куркытып кына калмый, китап укуга нәфрәт тә уятырга мөмкин. Китап уку сезнең өчен дә, балагыз өчен дә матур гадәткә әйләнсен. Укыганны истә калдыру өчен, мөһим урыннарны карандаш белән билгеләп яки блокнотка күчереп алып була. Күп укый торган кешеләр белән аралашу да китапка кызыксыну уятыр.

АЯЗ ӘГЪЛИУЛЛИН:

«МИН МОНЫ БУЛДЫРАМ, ДИП ЯШӘРГӘ КИРӘК»

«Шаян ТВ» телеканалы алып баручысы, 14 яшьлек Аяз Әгълиуллинның яшәү кагыйдәсе бу. Ул бер генә минутын да бушка уздырырга яратмый. «Берәр нәрсә телисең икән, шуңа ирешкәнгә кадәр туктамыйча барырга кирәк», – ди. Яшь, талантлы егет белән телевидение һәм театр, телне популярлаштыру һәм китаплар турында сөйләштек.

Кунагыбыз турында белешмә

- Аязга – 14 яшь;
- Казанның Совет районындагы 149 нчы лицеенда укый;
- «Апуш» татар балалар театр студиясендә шөгыльләнә;
- «Шаян ТВ» балалар телеканалында тапшырулар алып бара.

:: «Шаян ТВ» белән дуслык кайчан башланды? Анда нинди тапшырулар алып барасың?

– Телеканалда 3 ел тирәсе эшлим. Дустымның әнисе минем әнигә телеканал уздырган кастинг турында әйткән. Миңа әни шунда катнашып карарга тәкъдим итте һәм шулай итеп мин монда эләктем. «Шаян балалар», «Банка» тапшыруларын алып барам, «Калеб»тә катнашып, лайфхаклар тикшергәнебез бар.

:: Ә «Апуш»ка кайчан йөри башладың?

– Театрны бик яратам. «Апуш»та узган елның мартыннан бирле шөгыльләнәм. Төрле спектакльләр куябыз. «Апушның тылсымлы төшләре»ндә мин Сәгъди абзый ролен башкарам. «Зоопарк-әлифба» квест форматындагы спектакльдә Росомаханы уйнадым.

:: Җәйге каникул да узып бара, ял итеп өлгердеңме?

– Җәй башында бераз Казанда эшләр бар иде. «Апуш» белән имтиханнар тапшырдык, Сабан туйлар үткәрдек. Хәзер мин әбиләрдә, Кукмара районының Күкшел авылында.

:: Буш вакытларыңда нинди шөгыльләнәсең?

– Укыганда буш вакыт бик аз. Булса, файдалы итеп үткәрергә тырышам. Китаплар укырга яратам, музыка тыңлыйм, дуслар белән күрешәм.

:: Нинди китаплар укыйсың?

– 8 нче сыйныфта әдәбият дәресләрендә кайбер әсәрләрне укымый калган идек. Анда Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» пьесасы бар иде. Шуны бик яратып укып чыктым, аннары әни белән әсәрне анализладык. «Әлдермештән Әлмәндәр» – татар әдәбиятында миңа иң ошаган комедия. Чөнки ул тормышны яратырга, һәр мизгеленнән рәхәтлек алырга өйрәтә.

:: Телевидениедә дә эшлисең, театр белән дә мавыгасың. Ә киләчәктә үзеңне кайсы өлкәдә күрәсең?

– Дөресен генә әйткәндә, үзем дә белмим. Киләчәк турында уйларга куркам мин нигәдер *(көлә)*. Театр да, телевидение дә бик ошый. «Апуш»тагы остазыбыз безгә: «Киләчәк тормышыгызны театр белән бәйләмәсәгез дә, ул сезгә барыбер таяныч булып торачак», – ди.

:: Аерым алганда, театр һәм телевидениенең кайсы яклары ошый?

– Театр белән телевидение – җир белән күк арасы шикелле. Икесе ике төрле дөнья. Телевидениедә интервью аласың, кешеләр белән аралашасың, диалог корасың. Ә спектакльдә синә, бар дөньяңны онытып торып, рольгә керергә, шуның белән яшәргә кирәк. Әйе, телевидениедә дә, театрда да кешеләр белән эшлисең. Таләпләре дә бер: телең саф, чиста булырга тиеш, үзеңнең нәрсә эшләгәнеңне аңларга кирәк.

:: Тел мәсьәләсенә кагылгач, шунысын да билгеләп үтәсем килә: татар телең шундый саф, бик чиста сөйләшәсең. Бер дә шәһәр баласы димәссең. Гаиләдән киләме бу?

– Әйе, безнең гаиләдә татарча гына сөйләшәләр. Әнием белән әтием – бер авылдан. Нәселдә татар телендә генә сөйләшкәч, мәктәптә, дусларым белән дә туган телдә аралашкач, шулайдыр дип уйлыйм.

:: Ә яшьләр арасында телне ничек популярлаштырып була дип уйлыйсың?

– Аны бит аңлап та булмый. Ярый, без телне беләбез, ди. Ә башкаларга ничек җиткерергә? Әйтик, «Шаян ТВ»да татар телен популярлаштыру юнәлешендә эшлибез. Кечкенәдән телгә кызыксындыру уятыр өчен алар яратып карый торган мультфильмнарны татар теленә тәрҗемә итәбез, тавышландырабыз. Яшүсмерләр өчен татар телендә кызык тапшырулар әзерлибез.

:: Яшьтәшләреңә нинди киңәш бирер идең?

– Беренче чиратта, әлбәттә, ялкауланмаска. Вакыт-вакыт миндә дә була ул ялкаулык. Мин аның белән көрәшергә тырышам. Нинди генә эшкә тотынсаң да, аны ахырына кадәр җиткермичә, туктамаска кирәк. Берәр нәрсә телисең икән, шуңа ирешкәнгә кадәр бирешмәскә, алга барырга кирәк. Күбрәк чараларда катнашсыннар дип әйтер идем. Гел: «Мин моны булдырам», – дип торырга кирәк.

:: Бик максатчан, тырыш егет син. Бу сыйфатлар сиңа кайдан килә, дип уйлыйсың?

– Әти белән әни дә шундый минем. Әнием тәрҗемәче булып эшли. Ул – минем остазым. Әни миңа көч бирә, ярдәм итә. Киләчәгемне яхшы итеп күрәсем килә. Шуңа күрә тырышам, эшлим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Хикәя

Ярдәм

Урам уртасыннан карның каты кәсенә типкәләп барган Айрат үзенә дәшүләрен ишетеп туктап калды. Як-ягына карангалап торгач, ниһаять, агач янында басып торган сыйныфташы Рәзинәне күреп алды.

– Нәрсә кирәк? – диде ул, тавышын тамак төбеннән үк чыгарырга тырышып.

– Айрат, Айрат! Кил әле! Ярдәмең кирәк.

– Ни булды?

– Минә Йомшагым агач башына менеп китте дә төшә алмый. Нишләргә миңа хәзер?

Айрат югарыга, агач башына күтәрелеп карады. Чыннан да, анда аклы-каралы кечкенә генә песи баласы мияулап утыра иде. Өянкенең яше шактый, кәүсәләре бик юан, тотынып менәр өчен аскы өлешендә ботаклары да юк. Бары Айратның буе җитмәслек биеклектән генә икегә аерылып үсеп киткән. «Кызык, ничек шунда хәтле менә алды икән бу мәче баласы?» – дип уйлады ул эченнән генә.

Башын кашып бераз торгач, Айрат кар йомарлый башлады.

– Нишлисең син? – диде Рәзинә.

– Хәзер мәчеңне бәреп төшерәм. Борчылма, бер атуда тидерәм мин аңа!

– Атармын мин сиңа! Айрат, атма инде-е... Имгәтәсең бит Йомшагымны...

– Атам дигәч, атам!

– Айрат, агач башына үрмәләп кенә алып төш инде, зинһар?

– Юк! Бүген өй эшен күчертмәдең әле. Шуның аркасында тагын «икеле» алдым. Киттем мин...

– Айрат, тукта инде?! Песиемне алып төшеп бирсәң, һәр көнне өй эшен күчертер идем. Йә инде, Айрат!

– Һмм... Күчертәм дисең алайса?

– Әйе! Менәсеңме?

– Ярар! Кара аны, әгәр иртәгә алгебрадан дәфтәреңне бирмәсәң...

– Бирәм инде, бирәм!

Айрат, кулларын угалап, өянке янына килде, янә бер тапкыр агач башына карады. Ни гаҗәп: алар Рәзинә белән сөйләшкән арада, песи баласыннан җилләр искән иде!

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН

22 июль – Бөтендөнья баш мие көне

Баш мие көнен (World Brain Day) Бөтендөнья неврология федерациясе гамәлгә куя һәм аны ел саен 22 июльдә билгеләп үтәргә карар итә. Сезгә иң «акыллы» әгъза турында кызыклы фактлар тәкъдим итәбез.

Чәчәкләр дөньясында

Җиребез гаҗәеп матур. Аның бизәкләре – чәчәкләр. Җәй буе хуш исле лаләләр, розалар, лилияләр тирә-юньгә ямь биреп утыра. Питрәч районы Шәле авылының «Тургай» балалар бакчасында кәгазьдән матурлык тудырырга булганнар. Чәчәкләр тормышыбызны бизи, җанга рәхәтлек бирә.

Безгә язалар

Рәхмәт сиңа, авыл!

Җәйге айларда авыл икенче төрле сулый башлый кебек. Авылда туып, хәзер калага киткән кешеләр дә ешрак кайта, бакча тота, каникулда бала-чага әби-бабай янына ашыга. Элеккеге чалгы тавышы ишетелмәсә дә, һәр яктан электр чалгысы кошлар сайравын бүлә, ара-тирә матай тавышы ишетелә. Үзенең баласын җәйгә авылга алып кайту бәхетенә ия булган кеше: «Аллаһка шөкер, әле ярый авыл бар!» – дип җиңел итеп сулап куя. Үземнең дә балам туган ягым Яшел Үзән районы Урысбага авылында үсте, дисәң дә була. Җәй буе авылда дәү әтисе белән дәү әнисе янында, сөт эчеп, авылның табигый витаминлы ризыкларын ашап, сентябрьгә үсеп килә, әлхәмдүлилләһ. Авылыбыз да хәзер шәһәрдән калышмый. Кыш көне хоккей тартмасы булса, җәйгә футбол уйнар өчен бөтен шартларын китереп эшләнгән спорт мәйданчыгы бар. Бала-чага рәхәтләнеп туп тибә. Кечкенәләр өчен балалар мәйданчыгында төрле таганнар да урнаштырылган. Ә янәшәдәге Җиңү паркында эскәмияләр куелган. Балалы әниләр дә коляскалар белән рәхәтләнеп йөри ала. Моннан тыш, авылда каникулда ял итүче балалар өчен нинди генә чаралар үткәрелми. Авыл мәдәният йорты җитәкчесе Люция Садриева кышкы каникулда да, 1 июнь – Халыкара балаларны яклау көнендә дә төрле чаралар үткәреп тора. Күптән түгел генә узган балалар Сабан туе бәйрәме дә балаларга гына түгел, кайткан кунакларга да, авылдашларга да ошады. Бәйрәм чарасы малайлар арасында азан әйтүчеләр бәйгесе белән башланып китте. Коръән аятьләре, сүрәләрен яттан сөйләүче балалар да шактый иде. Узган ел авыл мәчетендә ике атналык җәйге укулар оештырылуның нәтиҗәсе бу. Укуларда дини белем белән берррәттән, әдәп-әхлак дәресләре, осталык буенча мастер-класслар үткәрелә, кызлар чигәргә дә өйрәнә. Ә малайлар азан әйтү серләренә төшенә. Калада яшәп тә, җәйгә авылда ике атна укуларга йөреп, шактый гына сүрәләр ятлап, татарча да әйбәт сөйләшә башлый сабыйлар. Ә инде ахырдан балалар өчен аерым бәйрәм дә үткәрелә. Узган ел өйрәнгән догаларын онытмаулары әби, дәү әниләрен бигрәк тә шатландырды. Кечкенәдән өйрәнгән сүрәләр онытылмый, дип әйтүләре шушыдыр, мөгаен. Быел да авылыбызда бу укулар башланып китте. 30га якын бала укуларга йөри башлады. Сабыйларыбызга файдалы гыйлемнәр алырга насыйп булсын иде. Авылыбыз мулласы Илшат Шиһапов мөселман бәйрәмнәрендә дә балаларны игътибарсыз калдырмый. Гает намазына килүче сабыйларны күчтәнәч белән сыйлый. Малайлар гаеттән шатланып кайта.

Бәйрәм чарасы мөнәҗәтләр әйтеп дәвам итте. Авылдашыбыз Фирая апаның оныклары Самат белән Рифат Бикмуллиннар, Зөһрә Җамалетдинованың мөнәҗәт әйтүе күпләрне сокландырды.

Балаларны туңдырма белән сыйлау, мөгаен, бәйрәмнең иң тәмле, мавыктыргыч минутлары булгандыр. «Балаларны шатландыра алуыбыз белән бәхетле. Һәр баланың балачагы күңелле мизгелләргә бай булсын. Ил-көннәребез тыныч булсын! Бәйрәмне оештыруда, бүләкләр алуда ярдәм иткән һәр кешегә рәхмәт яусын. Мондый бәйрәмнәребез дәвамлы булсын иде», – ди Урысбага авыл җирлеге башлыгы Хәйдәр Сибгатуллин.

Эш булса да, авылда узган каникул – иң рәхәт вакыт. Яшәсен авыллар, сәламәт булсын әби-бабайлар, диясе генә кала. Балалар өчен мондый чаралар оештыручыларга зур рәхмәт!

Руфия ИШМЕТОВА.
Казан – Яшел Үзән, Урысбага авылы

Сәхифәне Ләйсән САФИНА әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5315 данә
Гомуми тираж – 14253 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 304

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+